| СОВЕТ<br>БОЛЬШЕАЧАСЫРСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ОЛЫ АЧАСЫР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |
| --- | --- |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2025 елның 2 июле Олы Ачасыр авылы № 232

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге вәкаләтләренең бер өлешен җирлек торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Олы Ачасыр авыл җирлеге Советы **карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирлек торак пунктлары чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләсе буенча вәкаләтләренең бер өлешен Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшырырга:

- җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын паспортлаштыру.

2. Олы Ачасыр авыл җирлеге башкарма комитетына җирлекнең әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән торак пунктлары чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләсе буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты белән килешү төзергә.

3. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре составындагы Зеленодольск муниципаль

районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук мәгълүмат стендларында: Олы Ачасыр авылы, Үзәк урамы, 46 йорт (җирлек хакимияте бинасы), Олы Ачасыр авылы, Кооператив урамы, 26 йорт (авыл мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

Олы Ачасыр авыл жирлеге
башлыгы, Совет рәисе И.М. Саттаров